**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

25.03.2024 ел № 8

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 12 мартындагы «2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 7 санлы, 2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 8 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 12 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урале торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 7 санлы, 2023 елның 24 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 8 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Урал торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (зират территориясен коймаларны ремонтлау (төзү материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү));

2) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урал торак пунктын грейдерлау, юлларны кардан чистарту)».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы _______________ А.Г.Дәүләтгәрәев